Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлегенең Аккүл торак пунктында гражданнар җыены карары

2025 елның 29 ноябре №1

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлегенең Аккүл торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карары белән расланган (25.11.2024 №1049 редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Ивановка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 маддәсе белән, 2025 елның 29 ноябрендә узган «Сез Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлегенең Аккүл торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I-II төркем инвалидлар, мобилизацияләнгән һәм контракт буенча хәрбиләр, күпбалалы гаиләләрдән тыш, 2026 елда 1000 (Бер мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризамы:

) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Аккүл авылының Колхоз урамыннан (200 м)зиратка кадәр юлга вак таш салу; Аккүл авылының Күпер урамы, Колхоз урамы, Комсомол урамы буенча юлларны кардан чистарту);
2) торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (Аккүл авылында гомуми файдаланудагы территорияләрдә кулдан үлән чабу хезмәтләре күрсәтү);
3) су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Аккүл авылының Колхоз ур., 16Г адресы буенча каптаж ремонтлау)»соравы буенча узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 84 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 43 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында 43 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлегенең Аккүл торак пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлегенең Аккүл торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «Сез Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлегенең Аккүл торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I-II төркем инвалидлар, мобилизацияләнгән һәм контракт буенча хәрбиләр, күпбалалы гаиләләрдән тыш, 2026 елда 1000 (Бер мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризамы:

) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Аккүл авылының Колхоз урамыннан (200 м)зиратка кадәр юлга вак таш салу; Аккүл авылының Күпер урамы, Колхоз урамы, Комсомол урамы буенча юлларны кардан чистарту);

2) торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (Аккүл авылында гомуми файдаланудагы территорияләрдә кулдан үлән чабу хезмәтләре күрсәтү);

3) су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Аккүл авылының Колхоз ур., 16Г адресы буенча каптаж ремонтлау)» соравы буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң ун көн эчендә түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Ивановка авылы, Яшьлек ур., 5 й., Аккүл ав., Колхоз ур., 16Б; Медведкаав., Юл ур., 32; Михайловкаав., Үзәк ур., 4, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районының
Ивановка авыл җирлеге башлыгы А.П.Бодряева